# Арча яты язучылары



**Арча муниципаль районы мәгариф идарәсе**

**МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе»**

# Арча ягы язучылары

**Арча, 2021**

**Төзүчеләр:**

**Д.Ф. Мостафин,** МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе» директоры,

**Э.И. Газизова**, МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы,

**Г.Ф. Йосыпова**, МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы,

**З.Г. Шәфигуллина**, МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

**Арча ягы язучылары**. Арча, 15 март, 2021 ел.



# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ

(1886-1913)

Татар халык шагыйре Габдулла Тукай (Габдулла Мөхәммәтгариф улы Тукаев) 1886 елның 26 апрелендә элекке Казан губернасы Мәңгәр волосте (ТАССР Арча районы) Кушлавыч авылында туа. Кечкенәдән ятим калган Габдулла, кулдан-кулга йөреп, балачагын Сасна, Өчиле, Кырлай авылларында уздыра. Башлангыч белемне Кырлай авылы мәдрәсәсендә ала.

1895 ел башыннан Тукай Уральск шәһәрендә яшәүче туганнары гаиләсендә тәрбияләнә. Биредә ул татар халык иҗатын һәм әдәбиятын җентекләп өйрәнә, гарәп, фарсы, төрек, рус һәм башка халыкларның әдәбиятлары белән таныша, рус теле аркылы Көнбатыш классик әдәбияты казанышларын үзләштерә. Үзе дә беренче шигырьләрен иҗат итә.

Уральскидагы әдәби-мәдәни хәрәкәт Тукай тормышында хәлиткеч роль уйный. 1905 елгы революция дулкыны белән зур әдәбиятка килеп кергән әдип монда җәмәгать эшлеклесе, журналист, тәрҗемәче һәм шагыйрь буларак формалаша.

1907 елның көзендә Тукай Казанга кайта. Ул үлемсез әсәрләренең күбесен шушында яза; профессиональ революционерлар даирәсенә керә; татар культурасының революцион-демократик канатын җитәкләүгә алына. Шагыйрьнең сугышчан шигърияте һәм иҗтимагый, әдәби процессларның иң четерекле проблемаларына багышланган публицистик чыгышлары әдәби-мәдәни хәрәкәтнең төп юнәлешен билгеләүче көчкә әверелә.

Габдулла Тукай 1913 елның 15 апрелендә Казанда үпкә авыруыннан вафат була.



# ГОСМАН БАКИРОВ

(1896-1982)

Балалар язучысы һәм мәгариф эшлеклесе Госман Фәтхулла улы Бакиров 1896 елның 12 мартында Арча районы Югары Курса авылында урта хәлле игенче гаиләсендә туа. Җиде яшендә аны туган авылындагы җәдит мәдрәсәсенә укырга бирәләр. Мәдрәсәне тәмамлагач, уналты яшьлек Госман үзенең мөгаллимлек хезмәтен башлап җибәрә. 1923 елда Казанга килә һәм кичке Җир төзү техникумында укый.


1924 елда Г.Бакиров Көнчыгыш педагогия институтының кичке бүлегендә укый башлый. Бу елларда аның журналистик һәм әдәби иҗат эше дә бермә-бер активлаша: балалар сәхнәсе өчен «Беренче җиңү» (1928), «Яшәсен яшьләр» (1934), «Безнең рапорт» (1935), «Сафа балалары» (1936) исемле пьесалары языла, «Урак өсте» (1930) дигән хикәяләр җыентыгы басылып чыга, көндәлек матбугатта мәктәп һәм педагогикага кагылышлы дистәләрчә очерклары, мәкаләләре дөнья күрә; Татарстан дәүләт нәшриятында дәреслек китаплары һәм методик кулланмаларның кульъязмаларын басмага әзерләүдә якыннан катнаша.

1942 елда Г.Бакиров үзе теләп фронтка китә.

Сугыштан соң Г.Бакиров – яңадан Татарстан китап нәшриятында: 1945 елдан алып 1956 елга хәтле нәшриятның дәреслекләр бастыру редакциясенә мөдирлек итә. Әдәби иҗаты да тематик яктан баеп, сәнгатьчәлек юнәлешендә үсә бара. Аның «Партизан малай» (1952), «Классташлар» (1954), «Укытучым» (1963), «Утлы тегермән» (1965), «Бормалы юллар» (1982) повестьлары, «Мыеклы бикә», «Кадерле бүләк» кебек мәктәпкәчә яшьтәге балаларга адресланган китаплары сугыштан соңгы татар балалар әдәбияты хәзинәсендә лаеклы урын алып тора.

Госман Бакиров гомеренең соңгы көннәренә кадәр (ул 1982 елның 12 мартында Казанда вафат була) актив иҗат итә һәм җәмәгать тормышы белән яши. 1966 елда, җитмеш яше тулу уңае белән, аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелә.

Г.Бакиров – 1955 елдан СССР (Татарстан) Язучылар берлеге әгъзасы.



# ГОМӘР БӘШИРОВ

(1901-1999)

Гомәр Бәшир улы Бәширов 1901 нче елның 7 нче гыйнварында элеккеге Арча волостеның Яңа Сала авылында крестьян гаиләсендә туа. 7 яшеннән мәзиндә кыш буе белем ала, икенче елны мәдрәсәгә керә.

1919 нчы елның җәендә язучы Арча өязенең Урта Бирәзә авылында укытучы булып эшли башлый. 1920 нче елда яшь укытучы Кызыл Армиягә алына. Өч ел хезмәт итә. Армиядән кайткач, махсус курслар тәмамлап, совет милициясе һәм юстиция органнарында эшли. Ләкин әдәбиятка мәхәббәте аны журналистика өлкәсенә алып килә. 1932 нче елдан ул "Кызыл Татарстан" гәзитендә, бераздан "Совет әдәбияты" журналында эшли башлый. Аның бик күп мәкаләләре, очерклары, хикәяләре басыла. 1937 нче елда язучының атаклы "Сиваш" повесте басылып чыга. Бу әсәр бик тиз тарала һәм Г.Бәшировны күренекле язучылар сафына чыгара.

Язучының "Намус" романы аеруча уңыш казана. Ул 1948 нче елда басыла. Халыкның Ватан сугышы чорындагы фидакарь хезмәтен яктырткан бу әсәр өчен Гомәр Бәшировка 1951 нче елда икенче дәрәҗә ССРБ Дәүләт премиясе бирелә.


1968 нче елда язучы татар халкының гореф-гадәтләрен яктырткан "Туган ягым – яшел бишек" исемле автобиографик әсәрен тәмамлый. 1978 нче елда Г.Бәшировның "Җидегән чишмә" романы басылып чыга. Әсәр табигатьне саклау өчен көрәш темасына багышланган.

Г.Бәширов – фольклор әсәрләрен туплап, бастырып чыгару эшенә дә күп көч куйган язучы. "Туксан тугыз мәзәк", "Мең дә бер мәзәк" исемле китаплар – аның хезмәт нәтиҗәсе. Язучы әдәби тәнкыйть үсешенә дә үз өлешен кертә.

Гомәр Бәширов – озак еллар буе җәмәгать эшләре алып барган язучыларның берсе. Ул Татарстан Язучылар берлеге рәисе була. Берничә мәртәбә ССРБ һәм РСФСР Язучылар союзы идарәсе составына кертелә. Ике мәртәбә ССРБ Югары Шурасына депутат итеп сайлана.

"И язмыш, язмыш..." китабы өчен 1996 нчы елда Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнә.

1999 нчы елның 7 нче маенда Казанда вафат була.



# ӘНӘС ГАЛИЕВ

(1920-1996)

Шагыйрь һәм прозаик Әнәс Касыйм улы Галиев 1920 елның 3 апрелендә Татарстанның Арча районы Кушлавыч авылында мулла гаиләсендә туа. Бала чагында Тукай иҗатына һәм матур әдәбиятка гашыйк егет бик мавыгып шигырьләр язарга керешә.

Әнәс Галиев, җидееллык авыл мәктәбен тәмамлаганнан соң, 1936-1939 елларда Казан финанс-экономика техникумында махсус белем ала, аннары берникадәр вакыт Дөбъяз районы һәм Казандагы финанс органнарында инспектор булып эшли.

1940 елда Ә. Галиев армиягә алына, сугышның беренче көннәрендә үк алгы сызыкта була. 1942 елда контузияле хәлдә дошман кулына әсир төшеп, 1945 елга кадәр фашист концлагерьларында газап чигә. Беренче шигырьләре 1937 дә басыла. Ә.Галиев – «Сөю» (1940), «Кыен юл» (1958), «Тормыш бакчасында» (1960) исемле шигъри җыентыклар авторы.

1960 еллардан Ә.Галиев, нигездә, проза өлкәсендә иҗат итә. Фашист тоткынлыгының газаплары автобиографик характердагы «Йолдызлар шаһит» (1968), «Һәр солдатның үз язмышы» (1991) повестьларында чагылыш таба. Финанс оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә багышланган «Намус кушканча» (1982), «Җәза озак көттермәде» (1994) повестьлары да әдипнең тормыш тәҗрибәсеннән алынган. «Авылдашлар» (1995) романында фәлсәфи-психологик анализ аша кешенең эчке дөньясы ачып бирелә.

1996 елның 26 июлендә Казанда вафат була.

Әнәс Галиев – 1985 елдан СССР язучылар берлеге әгъзасы.



# РАФАИЛ ТӨХФӘТУЛЛИН

(1924-1994)

Рафаил Газиз улы Төхфәтуллин 1924 елның 1 гыйнварендa Татарстан АССРның хәзерге Арча районы Яңа Иябаш авылында укытучы гаиләсендә туган. Яңа Кенәр мәктәбенең тугызынчы классын тәмамлагач, Донбасска китеп, Горловка шәһәрендә ФЗӨ мәктәбендә укый, аннары шахтада забойщик булып эшли. 1941 елда эвакуация белән туган ягына кайта һәм унынчы класста укуын дәвам итә, курсларга йөреп, тракторчы профессиясен үзләштерә. 1942 елның августында армиягә алына, хәрби училищеда курслар үткәннән соң фронтка җибәрелә. Башта — пулеметчылар, аннары элемтәчеләр отделениесе командиры сыйфатында, ул Брянск, Орша һәм Рига шәһәрләре янындагы сугышларда катнаша, батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә. Ике тапкыр авыр яралана һәм бер тапкыр контузия ала. 1945 елның гыйнварендa армия хезмәтеннән азат ителә. Шул вакыттан алып 1957 елга кадәр Яңа Кенәрдә чыга торган «Кызыл юл» район газетасында җаваплы секретарь булып эшли. 1957—1959 елларда Мәскәүдә СССР Язучылар союзы каршындагы Югары әдәби курсларда укый.

1948 елда «Кызыл Татарстан» (хәзерге «Социалистик Татарстан») газетасында «Сабакташлар» исемле беренче хикәясе басыла. Хикәяләре тупланган беренче җыентыгы («Таныш гөрелте») 1954 елда дөнья күрә.

Рус теленнән тыш, Р. Төхфәтуллинның аерым әсәрләре күмәк җыентыкларда казакъ, үзбәк, каракалпак, чуваш, башкорт, телләрендә, ә «Җиләкле яланнар» исемле повесте чит илләр өчен чыгарыла торган «Советская литература» («Совет әдәбияты») журналының 1974 елгы санында инглиз, француз, немец, испан, поляк һәм чех телләрендә басыла.

1982—1983 елларда Татарстан китап нәшриятында әдипнең ике томлык «Сайланма әсәрләр» җыелмасы дөнья күрде.

Әдәбиятны үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен Р. Төхфәтуллин 1974 елда «Почет Билгесе» ордены белән бүләкләнде, ә 1984 елда Татарстан АССРның атказанган культура работнигы дигән мактаулы исемгә лаек булды.

Р. Төхфәтуллин—1955 елдан СССР Язучылар союзы члены иде. 1994 нче елда вафат булды.



# ГАРИФ АХУНОВ

(1925 – 2000)

Танылган әдип һәм җәмәгать эшлеклесе, Халык язучысы Гариф Ахунов (Гарифҗан Ахунҗан улы Ахунов) 1925 нче елның 18 нче сентябрендә Татарстан АССРның Арча районы Өчиле авылында крестьян гаиләсендә туган. Аның әтисе Ахунҗан абзый, авылның беренче коммунист-активистларыннан булып, күмәкләшү чорында ярлы крестьяннар арасында зур оештыру эшләре алып барган өчен, 1931нче елда кулаклар тарафыннан үтерелә. Әтисез калган дүрт баланы әниләре тәрбияләп үстерә. Күрше Казанбаш авылы мәктәбендә җиде класс белем алганнан соң, Гарифҗан 1940 нчы елда Арча педагогия училищесына укырга керә, ләкин Бөек Ватан сугышы башлану сәбәпле, укуын өзәргә мәҗбүр булып, колхозда эшли, 1946 нчы елда гына яңадан училищеда укуын дәвам иттерә. 1947—1952 нче елларда ул Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегендә укый.

Аның язучы буларак беренче иҗат тәҗрибәләре дә шушы студентлык елларына туры килә. 1951нче елда «Үсү юлы» альманахында яшь авторның «Галләм сорау бирә» исемле тәүге хикәясе басылып чыга.

1956 нчы елның көзендә Г. Ахунов республиканың нефть үзәге Әлмәт шәһәренә бер еллык иҗади командировкага бара. 1957 нче елны бөтенләй шунда күченеп, ун елдан артык нефтьчеләр арасында яши, аларның хезмәт казанышларын һәм көндәлек тормыш-көнкүрешен тирәнтен өйрәнә. Шул җанлы тормыш материаллары нигезендә, «Юллар чатында», «Хыялый Хәйрүш егетләре» җыентыкларын; «Артышлы тау буенда», «Канатлар кая илтә?» повестьларын, аннары зур күләмле әдәби әсәрләреннән «Хәзинә» һәм «Хуҗалар» исемле романнарын иҗат итә. Әлеге әсәрләре өчен Г. Ахунов 1973 нче елда Татарстан АССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була.



# ГӨЛЧӘЧӘК ГАЛИЕВА


(1928-2014)

Язучы-прозаик, әдәби тәнкыйть мәкаләләре һәм публицистик язмалар авторы Гөлчәчәк Кәрим кызы Галиева (Яхина) 1928 елның 5 февралендә Татарстанның Арча районы Сеже авылында укытучы гаиләсендә туа. Үз авылларында җидееллык һәм Арча педагогия училищесында урта педагогик белем ала. Читтән торып укып, 1954 елда Казан дәүләт педагогия институтының тарих факультетын тәмамлый. 1946 елдан мәктәптә укыта, мәктәп директоры хезмәтендә була.

Бала чактан әдәбиятка, туган телгә гашыйк Гөлчәчәк Галиева «Татар хикәясе ни хәлдә?», «Без белгән Бакый агамы?», «Язучы кем өчен яза?», «Каләм алдым кулыма», «Милләт каһарманы», «Чын сәнгать әсәре булсын», Рәфикъ Юныс иҗатына багышланган «Шагыйрь, публицист...» кебек иҗат портретлары һәм тәнкыйть мәкаләләре яза. «Тулгак» повесте аңа аеруча популярлык китерә. Ул «Ел китабы-2001» конкурсында II дәрәҗә Диплом белән бүләкләнә.

2003 елда әдибәнең «Тулгак» әсәрен һәм бүгенге җәмгыятьтәге кешеләр арасында барган астыртын көрәшнең нигезендә акча, байлык, комсызлык ятуын һәм шуңа бәйле булган төрле бозыклык, әхлаксызлык күренешләрен фаш иткән «Өзелгән өмет» исемле яңа повестен, хикәяләрен, мәкаләләрен, истәлек язмаларын үз эченә алган икенче китабы басылып чыга.

Г. Галиева 2001 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.



# МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ

(1930-1995)

Мөхәммәт Сөнгать улы Мәһдиев – Татарстан Республикасының халык язучысы, әдәби тәнкыйтьче, әдәбият галиме, укытучы.

Мөхәммәт Мәһдиев 1930 нчы елның 1 нче декабрендә Татарстанның Арча районы Гөберчәк авылында туган. 1944 нче елда Сикертән авылындагы җидееллык мәктәпне һәм 1947 нче елда Арча педагогия училищесын тәмамлаганнан соң, Сеҗе урта мәктәбендә бер ел өлкән пионервожатый булып эшли, аннары, 1948–1950 нче елларда, хәзерге Саба районының Керәнле җидееллык мәктәбендә тарих фәне укыта. 1950–1954 нче елларда Балтик хәрби флотында хезмәт итә. Фронттан кайткач, 1955–1960 нчы елларда Арча төбәге мәктәпләрендә укытучы булып эшли. 1959 нчы елда, читтән торып укып, Казан дәүләт педагогика институтының тарих бүлеген тәмамлый. 1960 нчы елда Казан дәүләт университетының татар әдәбияты кафедрасы каршындагы аспирантурага укырга керә.Аннары университетның татар әдәбияты кафедрасында башта ассистент, өлкән укытучы, ә 1968 нче елдан доцент булып эшли.

Мөхәммәт Мәһдиев – иҗат юлын әдәбиятчы һәм әдәби тәнкыйтьче булып башлаган язучы. Язучы-прозаик буларак исә анын исеме 1960 нчы елларда күренә башлый. 1967 елны «Казан утлары» журналында «Этюдлар» дигән гомуми баш астында аның беренче кыска хикәясе – әдәби парчалары басылып чыга, ә тагын бер елдан «Без – кырык беренче ел балалары» исемле повесте дөнья күрә. «Фронтовиклар» (1972) романы, «Каз канатлары» (1975) романы, «Кеше китә – җыры кала» (1978), «Торналар төшкән җирдә» (1978), «Ут чәчәге» (1980), «Исәнме, Кәшфи абый!» (1982) кебек повестьлары белән ул татар әдәбиятының алгы сафына баса.

«Кеше китә – җыры кала», «Торналар төшкән җирдә» , «Бәхилләшү» повестьлары өчен ул 1990 нчы елда Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була, 1993 нче елда исә халыкчан әдәби иҗаты өчен аңа Татарстан Президенты М.Ш.Шәймиев Указы белән «Татарстан Республикасының халык язучысы» дигән мактаулы исем бирелә.

Мөхәммәт Мәһдиев1995 нче елның 14 нче июнендә Казанда вафат булып, туган авылы зиратына җирләнә.



# РАДИК ФӘИЗОВ

(1931-2011)

Радик Фәизов 1931 елның 15 маенда Арча районының Дусым авылында туган. 1950елда Әтнә урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, бер ел үз авылларында башлангыч мәктәптә балалар укыта. 1951-1953 елларда Совет Армиясендә хезмәт итә; армиядән кайткач, саклык кассасы инспекторы, җир двигательләре монтажлаучы слесарь, пилорама мастеры һәм авиация заводында токарь булып эшли. 1957-1965 елларда ул Магниттау шәһәрендә яши  һәм эшли: паровоз кочегары, машинист ярдәмчесе була.

1965елдан башлап ул туган ягы Арча районының “Коммунизмга” газетасы редакциясендә  әдәби хезмәткәр, 1973 елдан  җаваплы сәркатип булып эшли. 1970 елда, читтән торып укып, Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлый.

Р. Фәизов – нигездә хикәяче. Аның эшчеләр, тимер юлчылар тормышыннан алып язылган беренче хикәяләре алтмышынчы еллар башында көндәлек матбугат битләрендә, аннан “Беренче адымнар” хикәясе күмәк җыентыкта басыла. Ул – “Яшьлек юллары” (1967) повесте, “Тимер чәчәк”, “Бәхет”, “Дусларым”, “Юлда” исемле хикәя җыентыклары авторы. Аларның барысы да заман кешесенең эчке дөньясын ачуга багышланган. 1983 елда  фантастик хикәяләре тупланган “Галәм кызы” исемле китабы басыла. “Чаян” журналында,  юмористик һәм сатирик хикәяләре дөнья күрә.

Р. Фәизов тормышка актив мөнәсәбәттә яши. Республика матбугатында ул хезмәт алдынгылары, мәгариф маяклары турындагы очерклары һәм публицистик мәкаләләре белән даими катнашып килә. Журналистика өлкәсендәге уңышлары һәм җәмәгать эшчәнлеге өчен 1981 елда аңа Татарстан АССРның атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исем бирелде. Р. Фәизов —1980 елдан СССР Язучылар союзы члены. 17 февраль 2011 елны вафат булды.



# ТӘБРИЗ МӨБАРӘКОВ

(1932-1996)

Тәбриз Мөбарәков әдәбият дөньясына атылган йолдыздай килеп керде һәм нечкә күңелле, йөгерек телле, укып туя алмаслык язучы булып танылды. Ул Арча районы Мөрәле авылында 1932 елның 21 февралендә дүртенче бала булып дөньяга килә.

Башлангыч белемне ул үз авылында, урта белемне Сеҗе мәктәбендә ала. КДУ ның физика-математика факультетын һәм аспирантура тәмамлап, физика-математика фәннәре кандидаты дәрәҗәсен ала. Көньяк Сахалинск һәм Алабуга педагогия институтларында, ә соңгы 25 елында Уфа авиация университетында укыта. Бер үк вакытта машиналар төзү өлкәсендә, физика-математика теорияләрен куллану буенча фәнни хезмәтләр яза. Аның бу хезмәтләре Европа галимнәре тарафыннан бик югары, хәтта яңа ачыш дип бәяләнә. Ә 1995 елны физика-математика галиме, беренче әдәби әсәре белән күпләрне таң калдырып, татар әдәбияты күгендә балкыды.

Галим һәм язучы Тәбриз Мөбәрәков гаҗәеп матур әдәби әсәрләр генә тудырып калмады, ялкынлы публицист буларак та кыюлыгы ягыннан аерылып торган мәкаләләре белән укучының игътибарын һәм хөрмәтен казанды.

Халык шагыйре Шәүкәт Галиев әдип вафатыннан соң түбәндәге юлларны язды:

Үтә язмышлар хәтәр араны:  
Күпме гомернең сүнеп калганы...  
Кайгы утының өтеп алганы,  
Кәккүк ник шулай саран санады?  
Онытмагыз, дип, сынап каравы-  
Тын гына тора “Хәтер аланы”...



# ГАЙСӘ ГАТАУЛЛИН

(1948–2007)

Язучы-прозаик Гайсә Госман улы Гатауллин 1948 елның 14 февралендә Татарстанның Арча районы Казиле авылында колхозчы гаиләсендә туа.

1965 елда Казанбаш урта мәктәбен тәмамлый. Мәктәптә уку елларында балта остасы һөнәрен үзләштереп, 1966–1970 елларда Казандагы 1 нче төзелеш трестының төзү-монтаж идарәләрендә слесарь һәм балта остасы булып эшли. Бер үк вакытта Казан авыл хуҗалыгы институтының читтән торып уку бүлегендә белем эстәвен дәвам итә, өченче курстан көндезге бүлеккә күчеп, 1973 елда институтны уңышлы тәмамлап чыга. Берничә ай Татарстанның Балык Бистәсе районы Корноухово совхозында инженер-механик булып эшләгәннән соң, бер ел гаскәри хезмәттә булып кайта. Г.Гатауллинның шуннан соңгы хезмәт юлы, нигездә, үз белгечлеге буенча дәвам итә: Казан моторлар төзү берләшмәсендә – мастер, Арча нефть базасында һәм Арча юл төзү идарәсендә – механик, «Сельхозтехника»ның Арча бүлегендә инженер һәм районның башка төзү-җитештерү оешмаларында механик һәм инженер вазифаларын башкара. Берара Төньякта, Якутиянең тайга җирләрендә дә булып кайта. Бу якларның табигате, кешеләре, шул җөмләдән төп халкы саналган якут һәм эвенкларның гореф-гадәтләре, көнкүреше турында аның «Еракларга китеп...» дип аталган юлъязмалары – документаль повесте һәм балаларга атап язылган «Тайга сукмаклары буйлап» исемле хикәяләр циклы да бар.

Гайсә Гатауллин яшь укучыларга хикәяләре, әкиятләре, юлъязмалары тупланган өч китабы белән таныш («Этнең койрыгы ник кәкре?», «Тавыш иле һәм батыр Черки», «Очар кошлар кебек»). Ул шигырьләр дә яза. Шигырьләре 2007 елда «Моң» дигән исемле китап булып басылып чыга. Язучы 2007 елда вафат була. Арча зиратына җирләнә.

Г.Гатауллин – 1995 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.



# ВАКЫЙФ НУРИЕВ

(1958 елда туган)

Балалар язучысы һәм журналист Вакыйф Вәкил улы Нуриев 1958 елның 17 августында Татарстанның Арча районы Сеже авылында туа.

Ул авылда урта мәктәпне тәмамлаганнан соң, 1975 елда Казан дәүләт университетының журналистика факультетына укырга керә. Бишенче курста укыганда ук, «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы редакциясендә әдәби хезмәткәр булып эшли башлый. Университетны тәмамлагач, «Яшь ленинчы» газетасы редакциясенә хәбәрче булып килә. Соңрак биредә җаваплы сәркатип, баш мөхәррир урынбасары вазифаларын башкара. 1987–1990 елларда В.Нуриев – Татарстан китап нәшриятында сәяси-тарихи әдәбият редакциясе мөдире хезмәтендә. 1990 елда В.Нуриевны яңа оешып килгән «Шәһри Казан» газетасына эшкә чакырып алалар. Биредә ул әүвәл бүлек мөхәррире, аннары 1995 елдан 2000 елга кадәр газетаның баш мөхәррир урынбасары булып эшли. 2000–2007 елларда Вакыйф Нуриев – «Салават күпере» һәм «Сәхнә» журналларының баш мөхәррир урынбасары хезмәтендә. 2004 елдан Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, 2007 елдан Татарстан Язучылар берлеге рәисе урынбасары.

Вакыйф Нуриев — 70кә якын хикәя авторы. 1990 елда Татарстан китап нәшриятында аның «Бүре кадәр бүрек» дигән хикәяләр җыентыгы дөнья күрде. 2006 елда аның «Җиденче палата», «Карга карагы», «Әбиесә — әфлисун» повестьлары дөнья күрә. Ул – Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстан Язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге әдәби бүләк иясе. 2018 елда «Фидакарь хезмәт өчен» Татарстанның дәүләт медале белән бүләкләнә.



# РӨСТӘМ ГАЛИУЛЛИН

(1987 елда туган)

Рөстәм Госман улы Галиуллин 1987 елның 26 ноябрендә Арча районы Наласа авылында туа. Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетын тәмамлый.

Студент елларында ук “Чаян” журналында, “Шәһри Казан” газетасында эшли. 2008-2010 елларда “Шәһри Казан” газетасында хәбәрче, бүлек мөхәррире, 2010 елның 1 ноябреннән “Казан утлары” журналының бүлек мөхәррире, 2011 елның 16 декабреннән 2014 елның ноябренә кадәр “Идел” журналының баш мөхәррире, 2015-2018 елларда Татарстан фәннәр Академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында өлкән фәнни хезмәткәр, гыйльми сәркатип вазифасын башкара, 2018 елның гыйнварыннан “Казан утлары” журналының баш мөхәррире.

Татарстан китап нәшриятында басылып чыккан “Гипнозчы малай” (2008), “Юлларда җил ак иде...” (2012) һәм “Васыять” (2017), Мәскәүдә рус телендә дөнья күргән “Одиночество” (2013) проза китаплары, “Тәуфикъ Әйди иҗаты: образлар системасы һәм жанр типологиясе” монографиясе (2016) авторы.

Рөстәм Галиуллин “Идел” яшьләр үзәге һәм Татарстан Язучылар берлеге оештырган “Иделем акчарлагы — 2007” бәйгесендә Гран-прига лаек була. 2015 елда “Юлларда җил ак иде” китабы һәм татар әдәбиятын үстерүгә керткән хезмәте өчен» Муса Җәлил премиясе бирелә.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

**Төзүчеләр:**

**Д.Ф. Мостафин,** МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе» директоры,

**Э.И. Газизова**, МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы,

**Г.Ф. Йосыпова**, МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы,

**З.Г. Шәфигуллина**, МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе» татар теле һәм әдәбияты укытучысы.

# Арча ягы язучылары

*Компьтерда биткә салучы –*

**А.Ф. Нагимов**

*Техник мөхәррир –*

**И.З. Файзуллин**

МБГБУ «Арча 6 нчы урта гомуми белем мәктәбе»ндә басылып чыккан.

422000, Арча,  ТАССРга 90 ел урамы, 42нчы йорт. Тел.: 8-843-663-33-30

E-mail: S6.Ars@tatar.ru